Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлеге Тукай торак пунктында гражданнар җыены

КАРАРЫ

«6» ноябрь 2020 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Яңа Иглай авыл җирлеге Тукай торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Яңа Иглай авыл җирлеге Тукай торак пункты территориясендә яшәүче һәр балигъ булган кешедән, 1 гр инвалидларыннан тыш, балачактан инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан, хәрби хәрәкәтләр ветераннарыннан, ялгыз яшәүче 75тән өлкәнрәк гражданнардан кала 2021 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

Тукай торак пункты чикләрендә авыл эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау;

Тукай торак пунктының урам утларын карап тоту һәм ремонтлау.

Халык җыенында рәислек итүче: Р.И. Фәйзуллин

Яңа Иглай авыл җирлеге башлыгы Р.И. Фәйзуллин